# Ислам нуры

اسلام نوری

«Диндә көчләү юк, ләкин өндәү һәм өйрәту бар»
(Коръән Кәрим. 2-256)

12+

№15 (739) 12 август 2021 ел (1443, мөхәррәм) Дини-иҗтимагый газета 1995 елдан чыга


*2021 ел - Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы*

## ЯҢА ЕЛ МӨБАРӘК БУЛСЫН!



Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

Әссәламүгаләйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһү.

Кадерле дин кардәшләрем! Газиз милләттәшләрем! Аллаһ Раббыбызга мактауларыбыз булсын! 9 август – мөбарәк, бөек һәм изге мөхәррәм аеның һәм һиҗри исәп буенча яңа 1443нче елның беренче көне. Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте һәм шәхсән үз исемемнән сезне әлеге мөһим дата белән ихлас күңелдән тәбриклим! Мөселман календаре безнең эраның 622 елыннан, пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) һиҗрәт кылган вакыттан, ягъни мөшрикләрнең кыерсытуларыннан һәм җәберләүләреннән качып, Рәсүлебезнең (с.г.в.) Мәккәдән Мәдинәгә күчүеннән исәпләнә башлаган. Мөселманча яңа ел мөхәррәм аеның беренче көнендә керә. Айның исеме “хәрәм” сүзеннән чыккан. Ә хәрәм айларда сугышлар алып бару, фетнәләр һәм дошманлашу тыела. Мөселманнар башкача бу айны Аллаһның ае дип тә йөртәләр. Шул рәвешле, календарь исәбен хәрәм айдан башлап җибәреп, Раббыбыз безгә үткән 12 айда алып барган тормышыбызга нәтиҗә ясарга, кылган гамәлләребез турында уйланырга һәм яңа елга дөрес, изге ниятләр белән керергә чакыра. Мөселманнар яңа елны әнә шулай каршы алырга тиеш: Аллаһы Тәгаләнең чиксез рәхим-шәфкатьләренә шөкер кылып, күрсәткән ярдәмнәренә рәхмәтләр белдереп, киләчәктә Аңа ихластан гыйбадәт кылырга, тәкъвалыгыбызны ныгытырга һәм изге гамәлләр кылырга дигән нияттә торып... Изге мөхәррәмнең тагын бер фазыйләте бар, ул – әлеге айның 10нчы көнендә билгеләп үтелүче Гашура көне. Мөхтәрәм дин кардәшләрем! Һиҗри исәп буенча яңа 1443 ел башлану уңаеннан Раббыбыз һәр гаиләгә бәрәкәтләр, безнең ихлас ниятләребезне тормышка ашыру өчен Үзенең хәер-фатыйхасын, илебезгә һәм җөмһүриятебезгә тынычлык, иминлек һәм бар мөселман өммәтенә игелекләр бирүен сорап догалар кылам. Аллаһы Тәгалә безгә яңа елда хак юлдан тайпылмыйча, Раббыбызның әманәтләрен һәм тәкъвалыгыбызны сакларга насыйп итсә иде. Әмин!

*Татарстан Республикасы мөфтие* **Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН**

## Ишетәсезме?..



Җәнабе Аллаһы колакларны файдалы нәрсәләр ишетү өчен яраткандыр. Шуның өчен алар белән Коръәни Шәриф вә мөбарәк хәдисләр, гыйбрәтле сүзләр ишетеп гамәл кылыгыз: ата-ана вә остазларыгызның нәсыйхәтләрен тыңлагыз! Бозык сүзләр ишетү гакылларга бозыклык китерер. Шуның өчен яман сүзләр ишетмәгез: яшеренеп сөйләнә торган сүзләрне тыңлап йөрмәгез! Һичкемнең күңеле исә моңа риза булмас. Сүз йөртүчеләр вә гайбәт сөйләүчеләрне тыңламагыз, күзегезне түбән салып тик торыгыз, үзегез белән бертигез булсалар — мондый эшләрнең яраклы түгеллеген әдәп белән аңлатыгыз, үзегездән кечкенәләр булганда, мәрхәмәт белән генә тыегыз. Ишеткән сүзләрдән фетнәгә сәбәп булачакларын һичкемгә сөйләмәгез!

**Риза ФӘХРЕДДИН** *(“Әхлак гыйлеме”ннән)*

## БЕЛЕМДӘ - КӨЧ



Мөхәррәм аеның 2нче көнендә, Кукмара районы Туеш авылы мәчетендә, Татарстанда игълан ителгән Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы уңаеннан, “Дин – телне, тел – динне саклый” дип исемләнгән районкүләм викторина үткәрелде, ул Кукмара районы мәчетләре имам-хатыйблары өчен оештырылды. Әлеге чараны үткәрүнең төп максатлары һәм бурычлары – татар мөселман традицияләрен саклау, мөселманнарда милли үзаң тәрбияләү, татар телле мохитне үстерү, XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында яшәгән күренекле татар дин галимнәренең татар теленә кагылышлы мирасын барлау һ.б. Чара барышында Кукмара районы имам-мөхтәсибе Рәдиф хәзрәт Тимергалиев, Татарстанның төньяк районнары казые Исмәгыйль хәзрәт Фәләхиев, Туеш мәчете имам-хатыйбы Айрат хәзрәт Шәфигуллин үз теләк-нәсихәтләрен белдерде. Зур Сәрдек авылы мәчете имам-хатыйбы Рифат хәзрәт Ибраһимов, Күкшел авылы мәчете имам-хатыйбы Рамил хәзрәт Садыйков, Каенлык авылы мәчете имам-хатыйбы Нәкыйп хәзрәт Халитов, Мәмәшир авылы мәчете имам-хатыйбы Вәгыйзь хәзрәт Нигъмәтуллин, Олыяз авылы мәчетенең икенче имамы Илназ хәзрәт Ибраһимов җиңүчеләр дип табылды.

## КУЛЫҢНАН КИЛСӘ, ИЗГЕЛЕК КЫЛ...

Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең «Зәкят» хәйрия фонды тарафыннан быел да «Мәктәпкә җыенырга ярдәм ит» республикакүләм акциясе игълан ителде. Акция Татарстанның күп балалы, азкеремле һәм инвалид балалар тәрбияләнүче гаиләләренә мәктәп кирәк-яраклары сатып алу өчен акча җыярга ярдәм итәчәк. Мәктәп букчасы комплекты үзгәрешсез булып кала: аңа канцелярия товарлары, дәфтәрләр, хезмәт һәм рәсем дәресләре өчен җыелмалар һәм башкалар керә. Әгәр сезнең бу изге гамәлдә катнашасыгыз килсә, сбербанк картасына 2202 2004 8668 4499 (Динар Дамирович З. – “Зәкят” фонды хезмәткәре) акча җибәрә аласыз. Безнең сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) болай дигән: «Яшермә, юкса Аллаһы Тәгалә сиңа бирергә мөмкин нәрсәләрне синнән яшерер, мөмкинлегеңә карап, Аллаһы юлында сарыф ит». Аллаһы Тәгалә сезнең изге эшләрегезне кабуллардан кылсын!






## УКУЛАР БАШЛАНА

Чаллы шәһәренең «Ак мәчет» мәдрәсәсе яңа уку елына абитуриентлар кабул итә. Торып уку – 2 ел һәм 10 ай; кичке уку – 3 ел һәм 10 ай; читтән торып уку – 3 ел һәм 10 ай.

Тулырак мәгълүмат алу өчен түбәндәге телефон номерларына шалтыратырга мөмкин: 8 (8552) 38-67-02, 8 917 919 27 48

# ӨММЕ СӘЛӘМӘ ТАРИХЫ

*(Ахыры. Башы газетаның алдагы санында)*

Күз алдына китерегез, хатынын сөекле иреннән, газиз баласыннан көчләп аералар. Аералар гына да түгел әле, улының кулын шартлатып сындыралар. Бу хатынның нилә̣р кичерүен күз алдына китерү дә авыр. Шулай булса да ул динен калдырмый! Диненә тугры кала! Дөнья нигъмәтләренә алданып динен корбан китерми.

Өмме Сәләмә болай дип дәвам итә: "Көн саен мин әл-Абтага, ирем белән баламнан аерылган җиргә барып, шушы хәлләрне исемә төшереп, елап утыра башладым. Шулай итеп бер елга якын вакыт узды". Күз алдына китерегез, бер ел! Аннан Аллаһы Тәгалә аның догасына җавап бирә: "Бервакыт туганнан туган абыем шушы төштән узып киткәндә минем хәлемне күрде. Ул элек тә миңа яхшы мөнәсәбәттә иде. Туры туганнарым янына барып, аларга: «И туганнарым! Азат итегез бу хатынны! Сез бит аны ире белән улыннан аердыгыз», - диде. "Башта баламны кайтарып бирделәр", - ди.

Аның ничек шатлануын күз алдына китерегез! Бераздан ире янына китәргә рөхсәт итәләр. Шуннан ул динен, гаиләсен саклап калган рәвештә, Мәккәдән чыгып китә һәм ире белән кавыша. Һичшиксез, ул Аллаһ юлында авырлыкларны сабырлык белән, Аллаһка буйсынып кичерүче хатын-кызлардан. Өмме Сәләмә үзе дә, ире дә диннәрен саклап калу өчен бар нәрсәләрен корбан итәләр. Бу дөньяның бөтен нигъмәтләреннән мәңгелек дөньяны артыграк күрәләр. Ире белән баласыннан аерып алуга, туганнары кире кагуга карамастан, диненә һәм иренә тугры калу, сынауларга бирешмәү - безнең чор хатын-кызлары өчен зур үрнәк!

Шуның белән сынаулар бетәме? Юк! Әбү Сәләмә Өхед сугышында катнашып, ук белән җәрәхәтләнә. Бер ай буена урын өстендә ята. Өмме Сәләмә ярасын дәвалап, иренең хәле җиңеләйгәнче, гел яныннан китми. Әмма күпмедер вакыттан соң иренең ярасы ачыла һәм ул вафат була. Иң яраткан кешесен югалта Өмме Сәләмә.

Ире үләр алдыннан гына бер вакыйга була. Өмме Сәләмә иренә: "Беләсеңме, мин нәрсә белдем, әгәр ире үлгәннән соң хатыны башкага кияүгә чыгудан баш тартса, һәм алар икесе дә җәннәткә керсәләр, Аллаһ аларны җәннәттә кавыштырачак. Әйдә, син иртәрәк үлеп китсәң, мин синнән соң беркемгә дә кияүгә чыкмыйм, мин иртәрәк үлеп китсәм, син өйләнмәячәксең дип, бер-беребезгә вәгъдә бирик", - ди. Әбү Сәләмә: "Син тыңлаячаксыңмы мине?" - дип сорый. Хатыны: "Әйе", - дип җавап бирә. Шуннан Әбү Сәләмә: "Әгәр мин иртәрәк үлеп китсәм, син кияүгә чыгарга тиешсең. Йә Аллаһ! Мин үлгәннән соң Өмме Сәләмәгә кайгыртучан, аңа берниндиזыян китерми торган, һәм миннән дә яхшырак ирне бир!" - дип дога кыла. Өмме Сәләмә аптырап кала - бу мөмкинме соң? Әбү Сәләмәдән дә яхшырак кем булсын?

Ире вафат булгач Өмме Сәләмә бик нык кайгыра. Бөтен Мәдинә шәһәре аның белән бергә кайгыга бата. Өмме Сәләмә сөйли: "Ирем вафат булганнан соң мин Пәйгамбәребез (с.г.в.) янына бардым һәм аңа: "И Аллаһның Илчесе, Әбү Сәләмә вафат булды", - дип әйттем. Ул миңа: "Йә Аллаһ! Мине һәм Әбү Сәләмәне ярлыка Һәм шуннан да яхшырак белән алыштыр!" - дип әйтергә кушты", - ди.

Бу сүзләрдән соң Өмме Сәләмә янә аптырап кала, ирен алыштырырлык, Әбү Сәләмәдән дә яхшырак кем булсын! Шулай булса да Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтергә кушкан доганы кабатлый.

Матәм вакыты тәмамлангач, мөселманнарның иң яхшылары: Әбү Бәкер, Гомер (Аллаһ алардан разый булсын) кияүгә чыгуын сорап киләләр. Әмма ул ипләп кенә, йомшаклык белән аларның тәкъдимнәрен кире кага.

Шуннан соң иң яхшы, иң күркәм кеше -Пәйгамбәребез (с.г.в.) үзе кияүгә алырга сорап килә аны. Күрегез, Аллаһы Тәгалә догага ничек җавап бирә! Өмме Сәләмә аңа: "Минем балаларым бар, бик көнчел мин, һәм кияүгә бирердәй махрамым да юк", - дип җавап кайтара. Икенче бер хәдистә "Шуның өстенә карт бит инде мин", - дип өсти.

Пәйгамбәребез (с.г.в.): "Яшь түгелмен дип әйтәсең, син яшәгәнне мин дә яшәгән. Яшь булмаган хатынның үзеннән зуррак яшьтәге кешегә кияүгә чыгуы оят нәрсә түгел. Балаларым бар дисең, синең балалар - алар минем дә балаларым. Һәм аларны тәэмин итү Аллаһы Тәгалә белән Аның Рәсүле өстендә. Көнчелмен дип әйтәсең, мин Аллаһтан сине аннан азат итүен сорармын", - дип җавап бирә. Бу сүзләрдән соң Өмме Сәләмәнең (Аллаһ аннан разый булсын) йөрәгендә борчый торган нәрсә калмый. Аллаһның Илчесе (с.г.в.) нең ачык һәм төгәл җавапларын ишеткәч, ул риза була һәм янындагы улы Гомәргә: "Йә Гомәр, тор! Рәсүлуллаһ белән безнең шаһитыбыз бул!" - ди.

Шулай итеп иреннән дә яхшырак, бөтен кешеләрдән дә яхшырак булган Пәйгамбәребез (с.г.в.) нең хатыны була. Карагыз, Аллаһы Тәгалә кешеләрнең догаларына ничек җавап бирә! Элегрәк Өмме Сәләмә, ягъни Сәләмәнең әнисе булса, хәзер ул Өмме мөэминин (кыямәт көненә кадәр иман китерүче бөтен мөселманнарның әнисенә) әйләнә. Нәкъ менә шушы зирәк хатын Пәйгамбәребез (с.г.в.) гә дөрес, акыллы киңәшләр бирә. Һәм ул хатыннары арасыннан иң соңгысы булып бу дөнья белән хушлаша. Аллаһ аннан разый булсын!

Йә Раббым Аллаһ, безнең хатыннарыбыз, апа-сеңелләребез, кызларыбыз, оныкларыбыз бу күркәм хатынга охшарга тырышсыннар, аннан үрнәк алсыннар! Бу дөньяда Үзеңнең ризалыгыңны алырга омтылып яшәсеннәр!

**Әбүбәкер хәзрәт ӘБДИЕВ,**
*Чаллының "Тәүбә" мәчете имам-хатыйбы*

## ГАШУРА КӨНЕ

Изге мөхәррәм аеның 10нчы көнендә билгеләп үтелүче Гашура көне быел 18нче августка туры килә. Ислам календареның беренче ае - мөхәррәм аедыр. Бу айның 10 нчы көне «Гашура көне» дип атала. Гарәп теленнән «гашура» дигән сүз «унынчы» дип тәрҗемә ителә. Пәйгамбәребез (с.г.в.) Мәккә шәһәреннән Мәдинә шәһәренә һиҗрәт кылганнан соң, шушы шәһәрдә яшәгән яһүдиләрнең бу көндә ураза тотканнарын күргән һәм алардан моның сәбәбен сораган. Яһүдиләр: «Бу көнне Аллаһы Тәгалә пәйгамбәребез Мусаны Фиргавеннән һәм аның гаскәреннән коткарган. Шуңа күрә без бу көнне зурлап ураза тотабыз», - дип җавап биргәннәр. Пәйгамбәребез (с.г.в.) аларга болай дип җавап биргән: «Муса пәйгамбәргә карата минем хокукым беренчедер...». Рәсүлебез Мөхәммәд (с.г.в.) үрнәк итеп шушы көнне уразада булган. Ул үзенең өммәтен, мөэмин-мөселманнарны да бу көндә ураза тотарга өндәгән. Гашура көнендә шактый күп бик әһәмиятле, тарихи, сөенечле вакыйгалар булган. Шуларның аеруча мөһим булганнары Аллаһның пәйгамбәрләре белән бәйледер. Бу көнне Бөек Раббыбыз бу дөньяны, Адәмне яраткан, нәкъ бу көнне Адәм галәйһиссәлам тәүбәсе кабул ителгән; Нух галәйһиссәлам көймәсе тауга килеп җитеп, андагы мөэминнәр туфаннан котылган; бу көнне Ибраһим пәйгамбәр туган һәм мәҗүсиләрнең учагыннан коткарылган, Гайсә һәм Идрис пәйгамбәрләр күккә ашкан; Муса пәйгамбәр һәм аңа ияргәннәр Фиргавеннең золымлыгыннан котылганнар, Фиргавенне шул көнне диңгез сулары йоткан; Юныс галәйһиссәлам балык карыныннан исән-имин чыгып котылган, Әюб пәйгамбәр авыр чирдән савыккан; озак елларга сузылган аерылышудан соң Якуб галәйһиссәлам улы Йосыф галәйһиссәлам белән очрашкан; Йосыф галәйһиссәлам зинданнан чыккан; Сөләйман пәйгамбәр патша булган. Шулай итеп, догалар, теләкләр кабул ителгән һәм бик күп бәла-казалардан котылуга сәбәп булганы өчен, Гашура көне котлы вә шатлыклы бер көн булып исәпләнә. Мөселманнар, Рамазан уразасы фарыз булганчы ук, Гашура уразасын тотып килгәннәр. Рамазан уразасы фарыз кылынгач, Гашура көне уразасы кешеләрнең ихтыярына калдырылган. Гашура көнне ураза тоткан кешеләр савaплы булыр. Бер хәдистә әйтелгәнчә, Гашура көнендә тотылган ураза мөселман кешене узган елда кылган гөнаһларыннан арындыра. Ә Гашура көнендә бирелгән бер бөртек сәдака өчен Аллаһы Тәгалә Өхед тавы кадәрле әҗер-савабын бирә. Шул ук көнне, ягъни мөхәррәм аеның 10 нчы көнендә яһүдиләр дә ураза тоткан өчен, Пәйгамбәребез: «Сез мөхәррәмнең 9 нчы һәм 10 нчы көннәрендә ураза тотып, алардан аермалы булып торыгыз», - дигән. Шулай итеп, Пәйгамбәребез галәйһиссәлам Гашурада ике көн, ягъни 9 һәм 10 мөхәррәмдә ураза тотуны киңәш иткән.

*("Ислам дине нигезләре"ннән)*

### СОРАУ-ҖАВАП

Укучылардан килгән сорауларга шәригать белгече **Рәфыйк хәзрәт МИННӘХМӘТОВ** җавап бирә.

**Сорау.** Хөрмәтле редакция! Үземне борчыган бер сорауга җавап табарга булышсагыз иде. Мин авыл җирендә яшим. Кайчагында, арып, ястү намазы кергәнче үк йокларга ятам. Уянгач, аны кайчанга кадәр укырга мөмкин? Иртәнге намаз кергәнчеме, әллә бу тәүлек беткәнчеме?

*Алдан ук рәхмәтле булып – Люция апагыз, Актаныш*

**Җавап.** Ястү намазының вакыты иртәнге намаз вакыты кергәнче дәвам итә. Ягъни календарьлардагы «сәхәр вакыты тәмам» дигән вакытка хәтле. Сәхәр вакыты тәмам булганнан соң укысагыз ястү намазын, ул каза санала. Сәхәр вакыты беткәнче укысагыз, вакытында укылган санала.

### ӘДӘБИ СҮЗ

### БӘХЕТЛЕМЕ СИН ДИП СОРЫЙЛАР

*“Бәхетлеме син?” - дип сорау бирә*
*Кайчагында миңа кешеләр.*
*Мин бәхетле, минем балаларым*
*Бәхет-тәүфыйк белән йөрсәләр.*
*Мин бәхетле, минем балаларым*
*Рәнҗетелмәсә нахакка.*
*Авыр, гадел юлдан бара алсалар,*
*Очрамасалар упкынга.*
*Мин бәхетле, минем балаларым*
*Гаделлекне өстен күрсәләр.*
*Мин бәхетле, минем оныкларым*
*Сау-сәламәт булып үссәләр.*

***Рәфисә Сәүбән кызы***

# ШӘҺАДӘТНАМӘ

– Кызым, бүген атна кич, барып дәү әниләреңнең идәнен юып кайтырга кирәк, – диде әнисе яңа гына мәктәптән кайткан баласына.

– Хәзер, бантикларымны гына салам да, – дип җавап кайтарды Әминә тиз генә ак бантикларын чәченнән чишә-чишә. Кыз мәктәп формасын салып урындык аркасына элде дә, альяпкычы белән урындыкны кочаклатып, бер бантигын урындыкның бер колагына, икенчесен икенче колагына тагып куйды. Аралыктан зәңгәр бөрчекле күлмәген тиз кенә киеп, дәү әниләренә чыгып китте.

Әминәнең дәү әтисе белән дәү әнисе ике тыкрык аша гына яши. Барырга озак түгел. Камрад бабайлар тыкрыгынннан узгач, Шәфика әбиләрнең капкасын үтәсең дә, дәү әтиләренең йорты да күренә башлый. Әминә Камрадлар тыкрыгыннан узганда бабайның бакчада кайнаша торган чагына туры килә. Гел алмагач янында бу бабай. Әллә өенә дә кереп тормый шунда. «Сәер исемле бу бабайны сугышта плиндә булган, немец телендә аның кушаматы «дус» дигәнне аңлата, – дип сөйләгән иде бервакыт дәү әтисе. – Аның исемен үзеннән башка беркем белми ди».

– Исәннәрдәмесез, Камрад бабай, – дип исәнләшә олыларча Әминә аның белән. Бабай авыз эченнән генә нәрсәдер җавап кайтара да:

– Кил әле якынрак, кил, – дип, дәшә. – Итәгеңне куй, – ди. Камрад бабайның алма бирәсен белеп торган Әминә, койма ярыгына итәген куя, аннан сап-сары алмалар тәгәп итәгенә төшә. Рәхмәт әйтеп, Әминә алмаларны кимерә-кимерә икенче тыкрыкка таба атлый.

Кем икәнен белер өчен кулын каш өстенә куйган Шәфика карчык Әминәнең якынрак килгәнен көтеп:

– Кая киттең кызым?! – дип юри сорый. Һәр атна саен алар тыкрыгыннан уза бит инде дәү әтиләренә. Ничә сораса да:

– Дәү әтиләргә, – дип җавап бирә кыз.

– Бәбекәем, кил әле кил, кәнфит бирәм, – дип кесәсеннән кәнфит чыгарып бирә балага Шәфика әби. Итәге тулы алмалар янына мендәр кәнфитлар да өстәлә. Шәфика карчыкка да, рәхмәт әйтеп, юлын дәвам итә Әминә.

Әминәнең дәү әнисе ничә еллар берни күрми – сукыр. Башта бер күзе белән шактый яшәде. Озак тормады, икенче күзе дә сукырайды. Күзе күрмәсә дә алар дәү әтисе белән икәү генә яшиләр. Ике тыкрык аша гына кызлары – Әминәнең әнисе була инде, яшәсәләр дә алар кәҗә савалар, сарык асрыйлар, тавык-чеби тоталар, бакчага бәрәңге дә чәчәләр. Кәҗәне дәү әтисе мөгезеннән тотып тора, дәү әнисе сава. Ашны да бергәләп пешерәләр: токмачны да кызлары кисеп китергәнне көтеп тормыйлар, бергәләп басалар да, дәү әнисе сукыр килешенә бик оста итеп кисә. Ничек кисә торгандыр?!. Шаккатмалы!!! Дәү әнисенең куллары бик сизгер, куллары гына түгел колаклары да бик яхшы ишетә – күзе генә күрми.

Атна кич Әминәнең идән юарга килүен алар белеп һәм көтеп торалар.

– Безнең Әминә мәктәптән кайтып җиткәндер инде, ике тулып китте. Сиңа әйтәм, озакламас, килеп тә керер, чәйнекне куя торыйм, – дип кулына дустыганын тотып чәйнеккә су салырга өлгерми – ишектән Әминә күренә. Алма ашый-ашый авызы камашып беткән кыз, иң беренче дәү әнисе янына килеп, аның җыерчыклы кулларын ала.

– Исәнме, дәү әни, бу мин – Әминә, – дип үзенең кем икәнен белдерә сукыр карчыкка. Әбисе аны сулышыннан ук таный. Аның нәзек учларын капшап:

– Килеп яхшы иткәнсең, сине көтеп тора идек, менә дәү әтиең чәй куеп җибәрер, мәктәптән кайткач, чәй дә эчәргә өлгермәгәнсеңдер әле, – дип, өстәлгә таба ымлый.

– Камрад бабай бер итәк алма бирде, Шәфика карчык тагын кәнфит тә бирде әле, – дип, итәгенә салынган байлыгын өстәлгә бушата Әминә.

– Ризыклы бала инде син, – дип куя дәү әнисе.

– И-и-и-и, кызым, – дип куәтләп ала дәү әтисе. – Бә-бе-кә-ем, бигрәк күп малың, – дип елмая. Аркасыннан сөеп, өстәл артына утырта.

Әминәнең дәү әнисе сүзчән түгел, «кызым», «балам» дигән сүзләрне гел әйтми. Кирәклесен генә әйтеп куя да бетте. Шуңа да аңа авыл халкы киңәшкә килә: хәсрәтен сөйли, шатлыгын бүлешә. «Асия карчык – ак карчык!» диләр аның дәү әнисенә. Дәү әтисе киресенчә – бөтен урам баласына «улым» йә «кызым» дип дәшә, әйтерсең бөтен авыл аның баласы, сүз саен «бәбекәем» генә дип тора.

Әминәнең атна кич дәү әниләренә идән юарга килүе чәй эчүдән башлана. Дәү әтисе өстәлгә шкафында булган бөтен тәмле нәрсәләрен чыгара. Бүген дә әнә, тәмле прәннек алып кайткан.

– Син бәбекәем килер дип алдым, – дип, сөйләнә-сөйләнә кәгазь пакеттан бушата прәннекләрен. Әминәнең Мәскәү апасы – әнисенең сеңлесе яңа гына җәйге ялга кайтып китте. Ул һәр елда, дәү әнисе белән дәү әтисенә кыш чыгарлык лимон, өрек, чикләвекле тортлар, әллә нинди тәмле кәнфитлар алып кайта ул. Дәү әтисе Әминәне шул тәмле әйберләр белән сыйлый. Бүген дә ул өстәлгә: киптерелгән банан, эче сары «Цитрон» кәнфитлар, «Гусиные лапки», «Снежок» дигәнен дә куйды. Әминә бигрәк тә сары эчле, тышы шоколадлы «Цитрон” белән чәй эчәргә ярата. Кәнфит кырыендагы шоколадларны кырып төшерә дә, алары белән аерым чәй эчә, аннан сары эчлеген ашап куя. Дәү әтисе аның шулай итеп утыруыннан: «И бала!» – дип сөя.

Моның хәтле тәмле әйберләргә, атнасына бер түгел, ике мәртәбә килеп идән юып китәрсең. Бик аптырап тормый анысы Әминә, авызы тәмле сораса, дәү әниләренә хәл белергә дип, мәктәптән туры кайта. Ләкин Әминәнең куанганы Мәскәү күчтәнәчләре дә түгел, ә алдагы бүлмәдә тумбочка тартмасына салынган саргаеп беткән кәгазьләр. Ике-өч кәнфитне бер чәшка чәй белән ялт иттергәннән соң, шоколадка буялган бармакларын ялый-ялый, ул алдагы бүлмәгә ашыга. Дәү әтисе Әминәгә идән юарга су хәстәрләп, чүпрәк алып кергәнче ул түрдәге тумбочкадан шул сары кәгазьләрне тартып чыгара. Пич аралыгында торган тузан чүпрәген алып тумбочканы сөртә-сөртә бала башлыгы эченә тутырылган кәгазьләрне караштырырга ярата ул.

Дәү әнисеннән: «Нинди кәгазьләр бу? – дип бер сорагач, – Салават-шәрифләр», – дип, кенә җавап биргән иде. «Нәрсә соң ул салават-шәрифләр? – дигәч, – Зекерләр, – диде. Үзенең бернәрсә дә аңламагын белдерергә теләмичә Әминә дәү әнисенә кабат сорау бирмәде. Ни дисәң дә, ул өченче классны тәмамлый, укый-яза белә, тарих белән кызыксына. Беренче класска кергәндә әкиятләрнең өч томын да укып чыккан иде. Берәр китап укыганда салават-шәрифнең дә нәрсә икәнен белермен әле дип, Әминә бу турыда бүтән сорамады. Ләкин рәсемле-хәрефләргә охшаган бу язуларны бик тә укыйсы килә иде аның. Дәү әнисе укырга өйрәтер иде дә – күзе күрми, дәү әтисенең күзе күрсә дә андый хәрефләрне укый белми иде. Эх! Таныса иде дә шул хәрефләрне, нәрсә язылганны укый алсаң иде. Болар бик могҗизалы хәрефләргә охшап торалар. «Әнә ниндидер ярымтүгәрк астына нокта куелган, тагын тарак теше кебеге дә бар, бака маймычына охшаганы нәрсә микән?» – дип, кулына шул сары кәгазьләрнең берсен алып, дәү әнисе янына килеп утырды.

– Дәү, әни, кара әле, бу язулар гел бертөрле башлана: ниндидер астына төртке куелган, ярымтүгәрәк нинди хәреф ул? – дип сорады. Дәү әнисе:

– «Б» булырга тиеш, – диде. Тарак теше кебеге – «с». – Бака маймычының – «м» икәнен белде Әминә. Бу хәрефләрнең гарәп хәрефләре, аларны уңнан сулга укырга кирәклеген дәү әнисе бер әйткән иде. Шулай хәреф җыештырып утыра торгач, идән юу да онытылды, дәү әтисе алып кергән су аралыкка куелган, кояш та әкрен генә баеп ята иде.

– Абау, идәнне юарга кирәк, – диде Әминә, дәү әтисе белән дәү әнисенә карап.

– Ярар, кызым ярар, – диде дәү әтисе, идән качмас, икенче җомга тагын җитә ул, икенче атнага, – диде, аны юатып. Дәү әтисе нишләптер бик шат иде.

– Кояш баеганда идән юарга кушмыйлар иде безгә, бар Әминә кайт, әле өй эшләреңне дә әзерлисең бар, укырга да күп биргәннәрдер, әниең дә борчылыр, дәү әтиең тыкрыкка хәтле озатып куяр, бар, бар, – дип өстәлдәге тәмле нәрсәләрне төенчеккә төенләп кызларын озаттылар дәү әтисе белән дәү әнисе.

Шушы балачак хәтирәләреннән аерылырга теләмичә яшел катыргы тышлы ярым ай төшерелгән шәһадәтнамәсен кулына алды Әминә. Бу вакыйгаларга утыз еллап вакыт узган. Аның итәгендә шәригать белгече һәм гарәп теле укытучысы дигән шаһадәтнамә. Әминә бу көннәргә ирешү өчен күпме юл узды: мәктәп бетерде, институт тәмамлады, гыйльми дәрәҗәләр дә алды, ләкин һәрвакыт балачак хыялына омтылып яшәде. Ничек тә булса дәү әнисендә сакланган рәсемле-хәрефләрне укыйсы, аңлыйсы килү теләге көчле иде. Бака маймычыннан башланган кызыксыну дәү әнисенең салават-шәрифләрен генә түгел, Корьәнне дә тану һәм укый алу бәхетенә китерде. «Эх, исән булсагыз, минем сөенечемне бүлешер идегез, бахыркайларым», – дип Әминә үзенең шәһадәтнамәсен бала башлыгы эченә куелган дәү әнисенең сары кәгазьләре янына тыгып, түр яктагы тумбочка тармасына салып куйды.

*Гөлфия НАСЫЙБУЛЛИНА*

# Сентябрь аена намаз вакытлары

| Милади сентябрь | Көн исеме | Мөхәррәм, сәфәр | Иртәнге намаз: Таң беленә Уфа | Таң беленә Чаллы | Таң беленә Казан | Мәчетләрдә укыла Уфа | Мәчетләрдә укыла Чаллы | Мәчетләрдә укыла Казан | Кояш чыга Уфа | Кояш чыга Чаллы | Кояш чыга Казан | Зәвал Уфа | Зәвал Чаллы | Зәвал Казан | Өйлә Уфа | Өйлә Чаллы | Өйлә Казан | Икенде Уфа | Икенде Чаллы | Икенде Казан | Ахшам Уфа | Ахшам Чаллы | Ахшам Казан | Ястү Уфа | Ястү Чаллы | Ястү Казан |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Чш | 24 | 04:23 | 02:09 | 02:22 | 04:53 | 03:05 | 03:18 | 06:23 | 04:35 | 04:48 | 13:16 | 11:30 | 11:43 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 16:59 | 16:10 | 16:23 | 20:08 | 18:24 | 18:37 | 21:38 | 20:18 | 20:32 |
| 2 | Пҗ | 25 | 04:25 | 02:12 | 02:25 | 04:55 | 03:06 | 03:19 | 06:25 | 04:36 | 04:49 | 13:16 | 11:30 | 11:43 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 16:58 | 16:08 | 16:21 | 20:06 | 18:21 | 18:35 | 21:36 | 20:15 | 20:28 |
| 3 | Җм | 26 | 04:27 | 02:16 | 02:28 | 04:57 | 03:08 | 03:21 | 06:27 | 04:38 | 04:51 | 13:15 | 11:29 | 11:42 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 16:56 | 16:06 | 16:19 | 20:03 | 18:19 | 18:32 | 21:33 | 20:12 | 20:25 |
| 4 | Шм | 27 | 04:28 | 02:19 | 02:31 | 04:58 | 03:10 | 03:23 | 06:28 | 04:40 | 04:53 | 13:15 | 11:29 | 11:42 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 16:54 | 16:04 | 16:17 | 20:01 | 18:16 | 18:29 | 21:31 | 20:08 | 20:22 |
| 5 | Як | 28 | 04:30 | 02:22 | 02:35 | 05:00 | 03:12 | 03:25 | 06:30 | 04:42 | 04:55 | 13:15 | 11:29 | 11:42 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 16:53 | 16:02 | 16:15 | 19:58 | 18:14 | 18:27 | 21:28 | 20:05 | 20:18 |
| 6 | Дш | 29 | 04:32 | 02:25 | 02:38 | 05:02 | 03:14 | 03:27 | 06:32 | 04:44 | 04:57 | 13:14 | 11:28 | 11:41 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 16:51 | 16:00 | 16:13 | 19:56 | 18:11 | 18:24 | 21:26 | 20:02 | 20:15 |
| 7 | Сш | 30 | 04:34 | 02:28 | 02:41 | 05:04 | 03:16 | 03:29 | 06:34 | 04:46 | 04:59 | 13:14 | 11:28 | 11:41 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 16:50 | 15:58 | 16:11 | 19:53 | 18:08 | 18:22 | 21:23 | 19:58 | 20:12 |
| 8 | Чш | 1 | 04:36 | 02:31 | 02:43 | 05:06 | 03:18 | 03:31 | 06:36 | 04:48 | 05:01 | 13:14 | 11:28 | 11:41 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 16:48 | 15:56 | 16:09 | 19:51 | 18:06 | 18:19 | 21:21 | 19:55 | 20:09 |
| 9 | Пҗ | 2 | 04:38 | 02:33 | 02:46 | 05:08 | 03:20 | 03:33 | 06:38 | 04:50 | 05:03 | 13:13 | 11:27 | 11:40 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 16:46 | 15:54 | 16:07 | 19:48 | 18:03 | 18:16 | 21:18 | 19:52 | 20:05 |
| 10 | Җм | 3 | 04:39 | 02:36 | 02:49 | 05:09 | 03:22 | 03:35 | 06:39 | 04:52 | 05:05 | 13:13 | 11:27 | 11:40 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 16:45 | 15:51 | 16:05 | 19:46 | 18:01 | 18:14 | 21:16 | 19:49 | 20:02 |
| 11 | Шм | 4 | 04:41 | 02:39 | 02:52 | 05:11 | 03:24 | 03:37 | 06:41 | 04:54 | 05:07 | 13:13 | 11:27 | 11:40 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 16:43 | 15:49 | 16:02 | 19:43 | 17:58 | 18:11 | 21:13 | 19:46 | 19:59 |
| 12 | Як | 5 | 04:43 | 02:42 | 02:55 | 05:13 | 03:26 | 03:39 | 06:43 | 04:56 | 05:09 | 13:12 | 11:26 | 11:39 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 16:41 | 15:47 | 16:00 | 19:41 | 17:55 | 18:08 | 21:11 | 19:43 | 19:56 |
| 13 | Дш | 6 | 04:45 | 02:45 | 02:57 | 05:15 | 03:28 | 03:41 | 06:45 | 04:58 | 05:11 | 13:12 | 11:26 | 11:39 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 16:39 | 15:45 | 15:58 | 19:38 | 17:53 | 18:06 | 21:08 | 19:39 | 19:53 |
| 14 | Сш | 7 | 04:47 | 02:47 | 03:00 | 05:17 | 03:30 | 03:43 | 06:47 | 05:00 | 05:13 | 13:12 | 11:25 | 11:39 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 16:38 | 15:43 | 15:56 | 19:35 | 17:50 | 18:03 | 21:05 | 19:36 | 19:50 |
| 15 | Чш | 8 | 04:49 | 02:50 | 03:03 | 05:19 | 03:31 | 03:45 | 06:49 | 05:01 | 05:15 | 13:11 | 11:25 | 11:38 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 16:36 | 15:41 | 15:54 | 19:33 | 17:47 | 18:01 | 21:03 | 19:33 | 19:46 |
| 16 | Пҗ | 9 | 04:51 | 02:52 | 03:05 | 05:21 | 03:33 | 03:47 | 06:51 | 05:03 | 05:17 | 13:11 | 11:25 | 11:38 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 16:34 | 15:39 | 15:52 | 19:30 | 17:45 | 17:58 | 21:00 | 19:30 | 19:43 |
| 17 | Җм | 10 | 04:52 | 02:55 | 03:08 | 05:22 | 03:35 | 03:48 | 06:52 | 05:05 | 05:18 | 13:11 | 11:24 | 11:37 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 16:32 | 15:36 | 15:49 | 19:28 | 17:42 | 17:55 | 20:58 | 19:27 | 19:40 |
| 18 | Шм | 11 | 04:54 | 02:58 | 03:10 | 05:24 | 03:37 | 03:50 | 06:54 | 05:07 | 05:20 | 13:10 | 11:24 | 11:37 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 16:31 | 15:34 | 15:47 | 19:25 | 17:40 | 17:53 | 20:55 | 19:24 | 19:37 |
| 19 | Як | 12 | 04:56 | 03:00 | 03:13 | 05:26 | 03:39 | 03:52 | 06:56 | 05:09 | 05:22 | 13:10 | 11:24 | 11:37 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 16:29 | 15:32 | 15:45 | 19:23 | 17:37 | 17:50 | 20:53 | 19:21 | 19:34 |
| 20 | Дш | 13 | 04:58 | 03:02 | 03:15 | 05:28 | 03:41 | 03:54 | 06:58 | 05:11 | 05:24 | 13:10 | 11:23 | 11:36 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 16:27 | 15:30 | 15:43 | 19:20 | 17:34 | 17:47 | 20:50 | 19:18 | 19:31 |
| 21 | Сш | 14 | 05:00 | 03:05 | 03:18 | 05:30 | 03:43 | 03:56 | 07:00 | 05:13 | 05:26 | 13:09 | 11:23 | 11:36 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 16:25 | 15:28 | 15:41 | 19:18 | 17:32 | 17:45 | 20:48 | 19:15 | 19:28 |
| 22 | Чш | 15 | 05:02 | 03:07 | 03:20 | 05:32 | 03:45 | 03:58 | 07:02 | 05:15 | 05:28 | 13:09 | 11:23 | 11:36 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 16:23 | 15:25 | 15:38 | 19:15 | 17:29 | 17:42 | 20:45 | 19:12 | 19:25 |
| 23 | Пҗ | 16 | 05:03 | 03:10 | 03:23 | 05:33 | 03:47 | 04:00 | 07:03 | 05:17 | 05:30 | 13:08 | 11:22 | 11:35 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 16:22 | 15:23 | 15:36 | 19:12 | 17:26 | 17:39 | 20:42 | 19:09 | 19:23 |
| 24 | Җм | 17 | 05:05 | 03:12 | 03:25 | 05:35 | 03:49 | 04:02 | 07:05 | 05:19 | 05:32 | 13:08 | 11:22 | 11:35 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 16:20 | 15:21 | 15:34 | 19:10 | 17:24 | 17:37 | 20:40 | 19:06 | 19:20 |
| 25 | Шм | 18 | 05:07 | 03:14 | 03:27 | 05:37 | 03:51 | 04:04 | 07:07 | 05:21 | 05:34 | 13:08 | 11:22 | 11:35 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 16:18 | 15:19 | 15:32 | 19:07 | 17:21 | 17:34 | 20:37 | 19:04 | 19:17 |
| 26 | Як | 19 | 05:09 | 03:17 | 03:30 | 05:39 | 03:53 | 04:06 | 07:09 | 05:23 | 05:36 | 13:07 | 11:21 | 11:34 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 16:16 | 15:16 | 15:29 | 19:05 | 17:19 | 17:32 | 20:35 | 19:01 | 19:14 |
| 27 | Дш | 20 | 05:11 | 03:19 | 03:32 | 05:41 | 03:55 | 04:08 | 07:11 | 05:25 | 05:38 | 13:07 | 11:21 | 11:34 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 16:14 | 15:14 | 15:27 | 19:02 | 17:16 | 17:29 | 20:32 | 18:58 | 19:11 |
| 28 | Сш | 21 | 05:13 | 03:21 | 03:34 | 05:43 | 03:57 | 04:10 | 07:13 | 05:27 | 05:40 | 13:07 | 11:21 | 11:34 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 16:12 | 15:12 | 15:25 | 19:00 | 17:13 | 17:26 | 20:30 | 18:55 | 19:08 |
| 29 | Чш | 22 | 05:15 | 03:24 | 03:37 | 05:45 | 03:59 | 04:12 | 07:15 | 05:29 | 05:42 | 13:06 | 11:20 | 11:33 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 16:10 | 15:10 | 15:23 | 18:57 | 17:11 | 17:24 | 20:27 | 18:52 | 19:06 |
| 30 | Пҗ | 23 | 05:16 | 03:26 | 03:39 | 05:46 | 04:01 | 04:14 | 07:16 | 05:31 | 05:44 | 13:06 | 11:20 | 11:33 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 16:09 | 15:07 | 15:20 | 18:55 | 17:08 | 17:21 | 20:25 | 18:50 | 19:03 |

*Балалар өчен*

**Фәйрүзә МӨСЛИМОВА**

## ТАТАР ӘЛИФБАСЫ

Өчпочмаклар – табын күрке
Өйгә кунак төшкәндә.
Гаиләбез белән бергә
Утырып чәй эчкәндә.



Гаиләнең хакы бик зур,
Безне яклый ул, саклый.
Кеше, читкә киткәндә дә,
Гаиләсен онытмый,
Туганнарын онытмый.

## ЯҢА КИТАП




Чаллыдагы “Ислам нуры” дини-эшмәкәрлек үзәгендә “Татар теле” дигән затлы, тирән эчтәлекле китап басылып чыкты. Аның авторы – Г. Батыршина. Китап югары дини уку йортларында укучы, татар телен дәвам итеп һәм туган тел буларак өйрәнүче студентлар өчен махсус төзелгән. Ун бүлекне үз эченә алган китап орфоэпик һәм орфографик темалардан тыш, “Аралашу әдәбе”, “Гаилә – бәхет ачкычы”, “Рухи-әхлакый кыйммәтләр” һ.б. турында файдалы, бай мәгълүматны чагылдыра. Төрле әсәрләрдән өзекләр, күренекле шәхесләр турында язмалар, вәгазьләр белән баетылып, киң катлам укучыларның да игътибарын җәлеп итә, алар өчен дә бик файдалы булып тора.

Китапны Чаллы шәһәре, ГЭС, Үзәк урам, 72 йорт адресындагы “Ислам нуры” дини-эшмәкәрлек үзәгеннән алырга мөмкин.

**Нәшире**
**Иршат Гыйльметдин улы ШӘЙХАТТАР**
**Баш мөхәррир**
**Муллагалиева А. Г.**
**Тел.:** (8552) 70-51-09
**Факс:** (8552) 70-51-45
* * *
**Оештыручылары:**
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте, “Ислам нуры” дини эшмәкәрлек Үзәге

Газета мәкаләләрен күчереп басканда аларның “Ислам нуры”ннан алынганын күрсәтү мәҗбүри.

Редакциягә килгән хатларда авторларның стиле саклана.

**Хатларны 423802, Чаллы Үзәк ур., 72 адресы буенча юллау кирәк.**

**Электрон хатлар өчен:**
islamgazeta@mail.ru

Мөселманнар арасын бозуга, үзара каршылыкларга китерергә мөмкин булган хатлар, шикаятьләр газетада басылмый.

Дин-шәригать мәсьәләләренә кагылышлы язмалар, укучы сораулары Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые, Чаллы төбәге мөхтәсибәтенең гыйльми Советы тарафыннан өйрәнелә һәм аларга җавап бирелә.

Россия Федерациясе матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникацияләр Министрлыгының Идел буе төбәкара территориаль идарәсендә ПИ № 7-0997 саны белән 2001 елның 15 ноябрендә теркәлде.

Айга ике мәртәбә чыга.

**Бу санның тиражы: 1100**
**Индексы 54149**

* * *

Хөрмәтле укучыбыз!

Газетабызны укып чыккач, аны туганнарыгызга, танышларыгызга тапшырсагыз иде. “Ислам нуры”ның һәр саны кулдан-кулга күчеп, динебезне таратырга ярдәм итсә иде. Әмин.

Шулай ук укучыларыбыз, Коръән аятьләре язылу сәбәпле, газетаны кирәкмәгән урыннарга ташлаудан сакланырлар дип ышанабыз.

* * *

Газета компьютерда җыелды, офсет ысулы белән “Ислам нуры” басмаханәсендә басылды.

**Нәшир, типография һәм редакция адресы:**
**423802, Яр Чаллы, Үзәк урамы, 72**

**Басарга кул куелды:**
**график буенча**
**12 август 16 сәг.**
**фактта 12 август 16 сәг.**
**Бәясе ирекле**